| ГЛАВА<br>Красноборского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Красный Бор авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.10.2025 Красный Бор авылы № 1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районы «Красный Бор авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегенең Красный Бор
торак пунктында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм
алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, 2003елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы "Җирле үзидрәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законның 25.156 статьясы, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы

45-ТРЗ номерлы Законның 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Красный Бор торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынының 1нче этабын 2025 елның 10 ноябрендә 10сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Красный Бор торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынының 2нче этабын 2025 елның 10 ноябрендә 13әгать 00 минутка билгеләргә

3. Халык исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга:

-1 этап: Көнчыгыш урам, Марс тавы урамы, Яңа урам, Краснобор урамы, Коммунальная урамы, Комлы урам, Тауасты урамы, Елга урамы, Маркин урамы, 1 - 27нче йортлар, Яшьлек урамы, Гагарин урамы, Яр буе урамы, Спорт урамы, Хезмәт урамы, Елга аръягы урамы.

-2 этап: Маркин урамы 37-63нче йортлар, Төзүчеләр урамы, Тау урамы, Урман урамы, Кама урамы, М.Горький урамы, Совхоз урамы, Яшьләр урамы, Сельхозтехника урамы, Октябрь урамы, Толстой урамы.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Девәтернә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, (I,II төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, иреклеләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балаларыннан) башка), 2026 елда үзара салым акчасын 700 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә, кулланута ризамы?

1) каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

2) торак пункт территориясен төзекләндерү,

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);

4) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм башка подстанцияләрне, алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, фонарьлар сатып алу һәм алмаштыру; урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

5) Хәрби дан паркы булдыру (җир кишәрлеген ызанлау, киртәләү, брусчатка ясау, яшелләндерү, эскәмияләр сатып алу һәм урнаштыру, яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Красный Бор авылы, Маркин урамы, 34нче йорт, авыл мәдәният сарае адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлегенең башкарма комитетына җыенны оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан

-2 этап: Маркин урамы 37-63нче йортлар, Төзүчеләр урамы, Тау урамы, Урман урамы, Кама урамы, М.Горький урамы, Совхоз урамы, Яшьләр урамы, Сельхозтехника урамы, Октябрь урамы, Толстой урамы.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Девәтернә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, (I,II төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекелләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балаларыннан) башка), 2026 елда үзара салым акчасын 700 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?

1) каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

2) торак пункт территориясен төзекләндерү,

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);

4) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм башка подстанцияләрне, алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, фонарьлар сатып алу һәм алмаштыру; урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

5) Хәрби дан паркы булдыру (җир кишәрлеген ызанлау, киртәләү, брустчатка ясау, яшелләндерү, эскәмияләр сатып алу һәм урнаштыру, яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Красный Бор авылы, Маркин урамы, 34нче йорт, авыл мәдәният сарае адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлегенең башкарма комитетына җыенны оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан

Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Е.А. Яковлева